**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**3 САНЛЫ КАРАРЫНА**

**КАРАР**

**№6 Акбаш ав. 04.03.2016 ел**

**2015 елның 15 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты арасында шәһәр (авыл) җирлеге территориясендә урнашкан һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек турында килешүне раслау хакында"гы 14 санлы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы карарын гамәлдән чыгару турында**

2015 елның 26 декабрендәге «Татарстан Республикасы муниципаль районнарының җирле үзидарә органнарына дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында»гы 109-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге Уставына таянып, Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы **карар итте:**

1.Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советының 2015 елның 15 июнендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты арасында шәһәр (авыл) җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән һәм шәһәр (авыл) җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән идарә итү мәсьәләләре буенча үзара хезмәттәшлек итү турындагы килешүне раслау хакында»гы 14 санлы карарын гамәлдән чыгарырга.

2.Әлеге карарны Ютазы муниципаль районы Советына җибәрергә.

3.Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы " Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең әлеге карарын түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Ютазы районы, Акбаш авылы, Мәктәп урамы, 17 йорт, һәм Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга http://jutaza.tatarstan.ru.

4.Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы: И. М. Миңнеханов